# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегенең Тенибәк авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2024 елның 25 марты № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның «25» мартында 13 сәгатьтә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, түбәндәге сорау буенча:

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегенең Тенибәк авылы «2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегенең Тенибәк авылы торак пунктында гражданнарга үзара салым кертү турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертүгә һәм «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегенең Тенибәк торак пунктында узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 7 номерлы карарына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча эшләр исемлеге өлешендә үзгәрешләр кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, төзекләндерү (койманы ремонтлау, смета документациясе төзү, төзелеш контроле үткәрү);
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү, смета документациясе төзү, төзелеш контроле үткәрү);
- Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (урам яктырту челтәрләрен карап тоту, смета документациясен төзү, төзелеш контролен үткәрү).

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә җыенда 21 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 12 кеше, бу 57,1% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: "ӘЙЕ" позициясе өчен гражданнар җыенында 12 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Тенибәк авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес.

2. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. 2024 елда алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, төзекләндерү (койманы ремонтлау, смета документациясе төзү, төзелеш контроле үткәрү);

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү, смета документациясе төзү, төзелеш контроле үткәрү);

- Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (урам яктырту челтәрләрен карап тоту, смета документациясен төзү, төзелеш контролен үткәрү).

4. Гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Өтәшкә ав., Нагорная ур., 99а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк, 40а йорт (мәдәният йорты бинасы).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Зеленодольск муниципаль районы
Өтәшкә авыл җирлеге башлыгы А.А. Клопов